Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының
«Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге
Варклэд-Бодья торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**23.11.2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "23" ноябрендә 10 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга: “2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варклэд-Бодья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, I төркем инвалидлардан, студентлардан тыш, көндезге формада белем алучы гражданнардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, ирекле киткән) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатыннарын, балигъ булмаган балаларын) түләүдән азат итү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Варклэд-Бодья торак пунктындагы юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм тракторчыга шартнамә буенча хезмәте өчен түләү, Варклэд-Бодья авылы Яшьләре урамы юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю);
2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (материаллар сатып алу) белән тәэмин итүче су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
3. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын карап тоту: ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу);
4. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру (электр товарларын сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру) өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 248 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 138 кеше кертелгән, бу 55,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 138 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Варкләд-Бодья торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. I төркем инвалидларыннан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Көчек авыл җирлеге территориясенең Варкләд-Бодья авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 600 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту(Варкләд-Бодья торак пунктындагы юлларны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу һәм тракторчыга шартнамә буенча хезмәте өчен түләү, Варкләд-Бодья авылы Яшьләре урамы юллары өчен вак таш сатып алу һәм җәю, су агымы өчен торбалар сатып алу һәм урнаштыру);

2. Су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (материаллар сатып алу) белән тәэмин итүче су башняларын, скважиналарны һәм башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

3. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын карап тоту: ягулык-майлау материаллары, запас частьләр алу);

4. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру (электр товарларын сатып алу һәм урам

яктырткычларын урнаштыру) өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау;

5. Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм алар тирәсендәге территорияләрне төзекләндерү (рөхсәтсез чүплекләрне бетерү);

6. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (күпер тактасын алыштыру өчен материаллар сатып алу).

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Х. Баһаутдинов